МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.10.2021 г.Казань № 794

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 23 ноябрендә 8182 номеры белән теркәлде

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2021 елның
«27» октябрендәге 794
номерлы боерыгы белән
расланды

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасындагы хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль яраклаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 15 сентябрендәге 649 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 28.09.2016 №549, 12.07.2018 №550, 10.09.2018 №842, 31.05.2019 №414, 16.11.2019 №1039, 15.05.2020 №297, 20.07.2020 №521, 28.09.2020 №675, 07.06.2021 №403 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасындагы хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль яраклаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.2 пунктта «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре – халыкның мәшгульлек үзәкләре (алга таба – мәшгульлек үзәге)» сүзләрен «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре (алга таба – мәшгульлек үзәге)» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында – http://mtsz.tatarstan.ru;

Татарстан Республикасы порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Бердәм порталда (http://www.gosuslugi.ru/).

Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа

тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла»;

1.9 пунктның дүртенче абзацында «(«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон))» сүзләрен «(«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон)) нигезендә тапшырылган») сүзләре белән алмаштырырга»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль яраклаштыру.

2.2. Башкарма хакимият органы (учреждениесе) атамасы

2.2.1. Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләре территориясендә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре күрсәтә.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан туры килә торган эшне мөстәкыйль эзләү, резюме төзү, эш бирүче белән эшлекле сөйләшү уздыру күнекмәләрен үстерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган форма буенча бәяләмәне мөрәҗәгать итүчегә бирү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь мөмкин булган вакыты:

индивидуаль хезмәт күрсәтү формасында – мөрәҗәгать итүчегә тест (анкета) уздыру вакытын исәпкә алмыйча, 8 сәгатьтән артык була алмый;

хезмәтне төркемдә күрсәтү формасында – мөрәҗәгать итүчегә тест (анкета) уздыру вакытын исәпкә алмыйча, 32 сәгатьтән артык була алмый.

2.4.2. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү «Федераль инвалидлар реестры» (алга таба – ФИР) федераль дәүләт мәгълүмат системасында булган инвалидлык турында белешмәләр, ә тиешле белешмәләр булмаса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.4.3. ФИР системасыннан инвалидлык турында кирәкле белешмәләрне алу мәшгульлек үзәге тарафыннан ФИР адресына ведомствоара электрон хезмәттәш-

лекнең бердәм системасын кулланып, электрон документ формасында җибәрелә торган ведомствоара рәсми мөрәҗәгать формалаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.4.4. ФИР системасыннан кирәкле белешмәләрне алу вакыты мөрәҗәгать итүче гариза тапшырган датадан башлап 7 эш көненнән артмаска тиеш.

2.4.5. Инвалидлар категориясенә керүче гражданнар өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь рөхсәт ителгән вакыты:

индивидуаль хезмәт күрсәтү формасында – мөрәҗәгать итүчегә тест (анкета) уздыру һәм кирәкле белешмәләрне ФИР алу вакытын исәпкә алмыйча, 8 сәгатьтән артык була алмый;

хезмәтне төркемдә күрсәтү формасында – мөрәҗәгать итүчегә тест (анкета) уздыру һәм кирәкле белешмәләрне ФИР алу вакытын исәпкә алмыйча, 32 сәгатьтән артык була алмый.

2.4.6. Мөрәҗәгать итүчеләр күпфункцияле үзәккә, КФҮ ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаны мәшгульлек үзәгенә тапшыру күпфункцияле үзәк белән мәшгульлек үзәге арасындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә срокларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

2.4.7. Дәүләт хезмәте алдан язылу буенча күрсәтелә. Дәүләт хезмәте күрсәтү көнен һәм вакытын килештерү мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта яки телефон яки электрон элемтә чараларын, шул исәптән Интернет челтәрен, почта элемтәсен дә кертеп, гаризаны теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

2.4.8. Алдан язылу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне көтү вакыты 5 минуттан артмаска тиеш.

2.4.9. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

### 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүче:

2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 13 нче кушымтадагы форма буенча гариза (алга таба – гариза) яки мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан бирелгән, 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 14 нче кушымтадагы форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимгә (алга таба – тәкъдим) ризалык тапшыра;

Россия Федерациясе гражданины (Россия Федерациясе гражданнары өчен) паспорты яисә аны алмаштыра торган документны, чит ил гражданины, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклый торган документны күрсәтә.

2.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы мәшгульлек үзәгенең рәсми сайтында, Татарстан

Республикасы порталында урнаштырылган.

2.5.3. Мөрәҗәгать итүчегә гариза тапшыру ысулын сайлау мөмкинлеге тәэмин ителә: халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, почта аша, электрон почтаны да кертеп, факсимиль элемтә ярдәмендә яисә гади электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында, шул исәптән Бердәм порталны яки Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып, яисә гаризаны күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша тапшыру юлы белән.

2.5.4. Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле килештерүләрне дә кертеп, һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итүгә бәйле гамәлләр башкаруны, 210-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән исемлекләргә кертелгән хезмәтләрне күрсәтү һәм әлеге хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсендә бирелә торган документларны һәм мәгълүматларны алудан тыш;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Организмдагы бозылган функцияләрне һәм яшәештәге чикләүләрне исәпкә алып, инвалид өчен медик-социаль экспертиза федераль дәүләт учреждениеләре (алга таба – МСЭ учреждениесе) тарафыннан киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлау өчен кирәкле, инвалидлык турындагы белешмәләрне үз эченә алган индивидуаль тернәкләндерү программасыннан өземтә ведомстволар арасында электрон хезмәттәшлек тәртибендә ФИР системасыннан алына.

2.6.2. Тиешле мәгълүматлар Инвалидларның федераль реестрында булмаса,

МСЭ учреждениесеннән бирелгән индивидуаль тернәкләндерү программасын инвалид үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы.

2.6.3. 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагында булган белешмәләрне үз эченә алган документларның тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе булып тормый.

### 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтүгә документлар кабул итүдән баш тарту өчен, КФҮ аша, КФҮ ерактагы эш урыны аша, почта элемтәсе, факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып яисә электрон рәвештә, шул исәптән Татарстан Республикасы бердәм порталын яисә бердәм порталны кулланып мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан иешенчә рәсмиләштерелмәгән, укып булмый торган яисә аның шәхси имзасы белән таныкланмаган яисә сүләрне кыскартып, аббревиатуралар кулланып тутырылган гаризаны тапшыруы нигез булып тора.

### 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Россия Федерациясе гражданины паспортын яки аны алмаштыра торган документның, чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документларның, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклый торган документларның булмавы яки аларны күрсәтүдән баш тартуы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар әлеге Регламентка 3 нче кушымтадагы форма буенча рәсмиләштерелә.

### 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры.

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән очракта чират көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.12.2. Дәүләт хезмәте алдан язылу буенча күрсәтелә. Дәүләт хезмәте күрсәтү көнен һәм вакытын килештерү мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта яки телефон яки электрон элемтә чараларын, шул исәптән Интернет челтәрен, почта элемтәсен дә кертеп, гаризаны теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

2.12.3. Вакыты һәм датасы алдан килештерелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне көтү вакыты 5 минуттан артмаска тиеш.

2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада

2.13.1. Гариза тапшырылган көнне.

2.13.2. Гаризаны теркәү халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар (физик затлар, эш бирүчеләр) регистрына мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда булган белешмәләрне исәпкә алу язуының теркәү номерын беркетеп кертү дигән сүз.

2.13.3. Мөрәҗәгать итүчеләр өчен гаризаны тапшыру ысулын сайлау мөмкинлеге тәэмин ителә: мәшгульлек үзәгенә яки күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына шәхсән мөрәҗәгать итеп, факсимиль элемтә чараларын кулланып яки электрон формада, шул исәптән бердәм портал яки Республика порталы аша.

2.13.4. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча гаризаны кабул итү датасы һәм исәпкә алу язуының теркәү номеры турында белешмәләрне үз эченә алган гариза күчермәсе бирелә ала.

2.13.5. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.7.1 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән хезмәт күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектлардан һәм күрсәтелә торган дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта,

объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтләре күрсәтү мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) хезмәт һәм мәшгульлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар һәм оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә комачаулый торган каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктaлы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) яки күрсәтеп булмау мөмкинлеге

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

бүлмәләрнең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм

порталда, Татарстан Республикасы порталында (http://uslugi.tatar.ru/) тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срокларыныэ үтәлүе;

дәүләт хезмәте күрсәтү срокларының үтәлүе;

мөрәҗәгать итүченең мәшгульлек үзәге белгечләре белән бәйләнешкә керү саны;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезлелеге;

мәшгульлек үзәге белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;

2.15.3. Мөрәҗәгать итүченең мәшгульлек үзәге белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.15.4. Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы әлеге Регламент белән билгеләнә.

2.15.5. Күпфункцияле үзәктә, ерактагы эш урынында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.15.6. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гариза теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча мәшгульлек үзәгенә тапшырыла.

2.15.7. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

2.15.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында, КФҮ алынырга мөмкин.

2.15.9. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

2.16.1. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.16.2. Гариза һәм документлар мәшгульлек үзәге бүлекчәсенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып электрон документ формасында җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан мәшгульлек үзәгенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль законда (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.»;

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны (гамәлләрне) дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре.

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 28 сентябрендәге 674 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 12.07.2018 №550, 10.09.2018 №842, 31.05.2019 №414, 16.11.2019 №1041, 15.05.2020 №297, 20.07.2020 №521, 28.09.2020 №675, 07.06.2021 №403 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.2 пунктта «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре – халыкның мәшгульлек үзәкләре (алга таба – мәшгульлек үзәге)» сүзләрен «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре (алга таба – мәшгульлек үзәге)» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Татарстан Республикасы порталы)» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 пунктның 2 пунктчасында:

өченче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Татарстан Республикасы порталы)» сүзләрен «Татарстан Республикасы порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/))» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла.»;

1.9 пунктның дүртенче абзацында «(«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон))» сүзләрен «(«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон)) нигезендә тапшырылган») сүзләре белән алмаштырырга»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү.

2.2. Башкарма хакимият органы (учреждениесе) атамасы

2.2.1. Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләре территориясендә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре күрсәтә.

2.2.2. Мәшгульлек үзәге тарафыннан килешү нигезендә җәлеп ителә торган, кирәкле белемнәре һәм эш тәҗрибәсе, психологик булышлык күрсәтү күнекмәләре булган, эшсез кешенең хезмәткә мотивациясен арттыру, эш эзләүгә карата аның позициясен активлаштыру, аның психологик торышын оптимальләштерү методларына ия булган белгечләр һәм (яки) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тиешле хезмәтләрне күрсәтергә хокуклы булган оешмалар (алга таба – мәшгульлек үзәге тарафыннан җәлеп ителгән белгечләр) тарафыннан дәүләт хезмәте (дәүләт хезмәтенең бер өлешен) күрсәтү рөхсәт ителә.

## 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

Мөрәҗәгать итүчегә хезмәткә карата мотивацияне арттыру, эш эзләү һәм эшкә урнашуга карата позицияне активлаштыру, профессиональ һәм социаль яктан үз урыныңны табу, булган шартларга яраклашу дәрәҗәсен арттыру, психологик торышны оптимальләштерү юлы белән һөнәри карьераны гамәлгә ашыру өчен каршылык булып торган психологик проблемаларны тулысынча хәл итү яки киметү буенча киңәшләрне үз эченә алган, 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә бирү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Дәүләт хезмәте алдан язылу буенча күрсәтелә. Мөрәҗәгать итүче белән дәүләт хезмәте күрсәтү көнен һәм вакытын килештерү мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта яки телефон яки электрон элемтә чараларын, шул исәптән Интернет челтәрен, почта элемтәсен дә кертеп, гаризаны теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

2.4.2. Алдан язылу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне көтү вакыты 5 минуттан артмаска тиеш.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь мөмкин булган вакыты:

индивидуаль хезмәт күрсәтү формасында – мөрәҗәгать итүчегә тест (анкета) уздыру вакытын исәпкә алмыйча, 90 минуттан артык була алмый;

хезмәтне төркемдә күрсәтү формасында – мөрәҗәгать итүчегә тест (анкета) уздыру вакытын исәпкә алмыйча, 4 сәгатьтән артык була алмый.

2.4.4. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү «Федераль инвалидлар реестры» (алга таба – ФИР) федераль дәүләт мәгълүмат системасында булган инвалидлык турында белешмәләр, ә тиешле белешмәләр булмаса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.4.5. ФИР системасыннан инвалидлык турында кирәкле белешмәләрне алу мәшгульлек үзәге тарафыннан ФИР адресына ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, электрон документ формасында җибәрелә торган ведомствоара рәсми мөрәҗәгать формалаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.4.6. ФИР системасыннан кирәкле белешмәләрне алу вакыты мөрәҗәгать итүче гариза тапшырган датадан башлап 7 эш көненнән артмаска тиеш.

2.4.7. Инвалидлар категориясенә керүче гражданнар өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь рөхсәт ителгән вакыты:

индивидуаль хезмәт күрсәтү формасында – мөрәҗәгать итүчегә тест (анкета) уздыру һәм кирәкле белешмәләрне ФИР алу вакытын исәпкә алмыйча, 90 минуттан артык була алмый;

хезмәтне төркемдә күрсәтү формасында – мөрәҗәгать итүчегә тест (анкета) уздыру һәм кирәкле белешмәләрне ФИР алу вакытын исәпкә алмыйча, 4 сәгатьтән

артык була алмый.

2.4.8. Мөрәҗәгать итүчеләр күпфункцияле үзәккә, КФҮ ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаны мәшгульлек үзәгенә тапшыру күпфункцияле үзәк белән мәшгульлек үзәге арасындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә срокларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

2.4.9. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар – физик затлар регистрын (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистры (эш бирүчеләр банкы)) үз эченә алган программа-техника комплексында теркәүгә бәйле административ процедураларны гамәлгә ашыруның максималь мөмкин булган вакытлары 20 миунттан артмаска тиеш.

2.4.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча язмача мөрәҗәгатькә, электрон почта, факсималь элемтә чараларын кулланып алынган мөрәҗәгатьне дә кертеп, җавап әзерләү срогы мөрәҗәгатьне теркәү мизгеленнән 15 календарь көннән артмаска тиеш.

2.4.11. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

### 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүче:

2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 13 нче кушымтадагы форма буенча гариза (алга таба – гариза) яки мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан бирелгән, 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 14 нче кушымтадагы форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимгә (алга таба – тәкъдим) ризалык тапшыра;

Россия Федерациясе гражданины (Россия Федерациясе гражданнары өчен) паспорты яисә аны алмаштыра торган документны, чит ил гражданины, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклый торган документны күрсәтә.

2.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы мәшгульлек үзәгенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы порталында урнаштырылган.

2.5.3. Мөрәҗәгать итүчеләргә гариза тапшыру ысулын сайлау мөмкинлеге тәэмин ителә: халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, почта аша, электрон почтаны да кертеп, факсимиль элемтә ярдәмендә яисә гади электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында, шул исәптән Бердәм порталны яки Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып, яисә гаризаны күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша тапшыру юлы белән.

2.5.4. Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле килештерүләрне дә кертеп, һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итүгә бәйле гамәлләр башкаруны, 210-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән исемлекләргә кертелгән хезмәтләрне күрсәтү һәм әлеге хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсендә бирелә торган документларны һәм мәгълүматларны алудан тыш;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Организмдагы бозылган функцияләрне һәм яшәештәге чикләүләрне исәпкә алып, инвалид өчен медик-социаль экспертиза федераль дәүләт учреждениеләре (алга таба – МСЭ учреждениесе) тарафыннан киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлау өчен кирәкле, инвалидлык турындагы белешмәләрне үз эченә алган индивидуаль тернәкләндерү программасыннан өземтә ведомстволар арасында электрон хезмәттәшлек тәртибендә ФИР системасыннан алына.

2.6.2. Тиешле мәгълүматлар Инвалидларның федераль реестрында булмаса, МСЭ учреждениесеннән бирелгән индивидуаль тернәкләндерү программасын инвалид үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы.

2.6.3. 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган

дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагында булган белешмәләрне үз эченә алган документларның тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе булып тормый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре юк.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Россия Федерациясе гражданины паспортын яки аны алмаштыра торган документның, чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документларның, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклый торган документларның булмавы яки аларны күрсәтүдән баш тартуы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар әлеге Регламентка 3 нче кушымтадагы форма буенча рәсмиләштерелә.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

## 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

## 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Дәүләт хезмәте алдан язылу буенча күрсәтелә. Дәүләт хезмәте күрсәтү көнен һәм вакытын килештерү мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта яки телефон яки электрон элемтә чараларын, шул исәптән Интернет челтәрен, почта элемтәсен дә кертеп, гаризаны теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

2.12.2. Гаризаны теркәү халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда булган белешмәләрне исәпкә алу язуының теркәү номерын беркетеп кертү дигән сүз.

2.12.3. Чиратта тору вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.12.4. Вакыты һәм датасы алдан килештерелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне көтү вакыты 5 минуттан артмаска тиеш.

2.12.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь мөмкин булган вакыты:

индивидуаль хезмәт күрсәтү формасында – эшсез гражданинга тест (анкета) уздыру вакытын исәпкә алмыйча, 90 минуттан артык була алмый;

хезмәтне төркемдә күрсәтү формасында – эшсез гражданинга тест (анкета) уздыру вакытын исәпкә алмыйча, 4 сәгатьтән артык була алмый.

### 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада

2.13.1. Гариза тапшырылган көнне.

2.13.2. Гаризаны теркәү халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар (физик затлар, эш бирүчеләр) регистрына мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда булган белешмәләрне исәпкә алу язуының теркәү номерын беркетеп кертү дигән сүз.

2.13.3. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча гаризаны кабул итү датасы һәм исәпкә алу язуының теркәү номеры турында белешмәләрне үз эченә алган гариза күчермәсе бирелә ала.

2.13.4. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле

мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.7.1 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән хезмәт күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектлардан һәм күрсәтелә торган дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтләре күрсәтү мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) хезмәт һәм мәшгульлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар һәм оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә комачаулый торган каршылыкларны

бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) яки күрсәтеп булмау мөмкинлеге

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:

мөрәҗәгать итүче өчен индивидуаль яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү рәвешендә (шәхси кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларын кулланып, массакүләм мәгълүмат чараларында мәкаләләр, мәгълүмати материаллары (брошюралар, белешмәлекләр, буклетлар һ.б.) нәшер итү юлы белән) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турында Татарстан Республикасы порталында мәгълүмат урнаштыру мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүче өчен дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаларның һәм башка документларның формаларын алуны, шул исәптән аларны күчереп алу һәм электрон рәвештә тутыру мөмкинлеге белән дә, тәэмин итү;

гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтү вакытының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, шул исәптән телефон элемтәсе, электрон почта аша, Бердәм портал һәм Татарстан Республикасы порталы, күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүмат алу мөмкинлеге;

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачаулаган каршылыкларны бетерүдә ярдәм итү;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срокларыныэ үтәлүе;

дәүләт хезмәте күрсәтү срокларының үтәлүе;

әлеге Регламентта билгеләнгән административ процедураларның эзлеклелеге саклану;

мөрәҗәгать итүченең мәшгульлек үзәге белгечләре белән бәйләнешкә керү саны;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезлелеге;

мәшгульлек үзәге белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;

2.15.3. Мөрәҗәгать итүченең мәшгульлек үзәге белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

документларны почта аша җибәргәндә, шул исәптән электрон документ формасында да – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.15.4. Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы әлеге Регламент белән билгеләнә.

2.15.5. Күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.15.6. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гариза теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча мәшгульлек үзәгенә тапшырыла.

2.15.7. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

2.15.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында, КФҮ алынырга мөмкин.

2.15.9. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

2.16.1. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүдән тыш, электрон формада күрсәтелми.

2.16.2. Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар мәшгульлек үзәге бүлекчәсенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан мәшгульлек үзәгенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза

гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль законда (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш»;

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны (гамәлләрне) дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре.

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

6 нчы бүлекне гамәлдән чыккан дип танырга;

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында, эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнаштыру, һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында, гражданнарга һөнәри юнәлеш бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 13 ноябрендәге 625 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 17.11.2015 №839, 07.06.2016 №317, 27.09.2018 №907, 31.05.2019 №414, 16.11.2019 №1038, 15.05.2020 №297, 20.07.2020 №521, 28.09.2020 №675, 07.06.2021 №403 боерык-лары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында, эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнаштыру, һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында, гражданнарга һөнәри юнәлеш бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.2 пунктта «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре – халыкның мәшгульлек үзәкләре (алга таба – мәшгульлек үзәге)» сүзләрен «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре (алга таба – мәшгульлек үзәге)» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Татарстан Республикасы порталы)» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 пунктның 2 пунктчасында:

өченче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасында

(http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Татарстан Республикасы порталы)» сүзләрен «Татарстан Республикасы порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/))» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацка «(алга таба – бердәм портал)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла.»;

1.9 пунктның дүртенче абзацында «(«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон))» сүзләрен «(«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон)) нигезендә тапшырылган») сүзләре белән алмаштырырга»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Татарстан Республикасында эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә уку һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү.

### 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждениесе) атамасы

2.2.1. Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләре территориясендә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре күрсәтә.

2.2.2. Мәшгульлек үзәге тарафыннан килешү нигезендә чакыртыла торган, кирәкле белемнәре һәм эш тәҗрибәсе булган, гражданнарга һөнәри юнәлеш биргәндә кулланыла торган методларга, методикаларга, гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү тренинглары һәм технологияләре формаларына ия булган белгечләр һәм (яки) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тиешле хезмәтләрне күрсәтергә хокуклы булган оешмалар тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтү (дәүләт хезмәтенең бер өлешен күрсәтү) рөхсәт ителә.

### 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

Аларны гамәлгә ашырган вакытта мөрәҗәгать итүченең профессиональ һәм эшкуарлык эшчәнлегенә уңышлы ирешә алуы мөмкин булган һөнәри эшчәнлекнең, мәшгульлекнең һәм компетенцияләрнең киңәш ителә торган, билгеле бер өлкәдә һөнәри эшчәнлек алып бару һәм (яки) конкрет һөнәрләр, белгечлекләр буенча эшләр башкару мөмкинлеген бирә торган төрләрен, һөнәргә укыту һәм (яки) һөнәри белем, өстәмә һөнәри белем алуның мөмкин булган юнәлешләрен үз эченә алган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы бәяләмәне бирү; 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган формала буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы бәяләмә нөсхәсен мөрәҗәгать итүченең шәхси эшенә теркәп кую дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып тора.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Тест (анкета) һәм тренинг уздыру вакытын исәпкә алмыйча, гражданнарга дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь мөмкин булган вакыты 60 минуттан артып китмәскә тиеш.

2.4.2. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү «Федераль инвалидлар реестры» (алга таба – ФИР) федераль дәүләт мәгълүмат системасында булган инвалидлык турында белешмәләр, ә тиешле белешмәләр булмаса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.4.3. ФИР системасыннан инвалидлык турында кирәкле белешмәләрне алу мәшгульлек үзәге тарафыннан ФИР адресына ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, электрон документ формасында җибәрелә торган ведомствоара рәсми мөрәҗәгать формалаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.4.4. ФИР системасыннан кирәкле белешмәләрне алу вакытының озынлыгы мөрәҗәгать итүче гариза тапшырган датадан башлап 7 эш көненнән артмаска тиеш.

2.4.5. Инвалидлар категориясенә керә торган гражданнар өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь мөмкин булган вакыты, мөрәҗәгать итүчегә тест (анкета) уздыру һәм ФИР системасыннан кирәкле белешмәләрне алу вакытын исәпкә алмыйча, 60 минуттан артык булырга тиеш түгел.

2.4.6. Мөрәҗәгать итүче беренче тапкыр мәшгульлек үзәгенә яки КФҮ, КФҮ ерактагы эш урынына шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте чират тәртибе күрсәтелә.

2.4.7. Мөрәҗәгать итүчеләр күпфункцияле үзәккә, КФҮ ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаны мәшгульлек үзәгенә тапшыру күпфункцияле үзәк белән мәшгульлек үзәге арасындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә срокларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

2.4.8. Дәүләт хезмәте мәшгульлек үзәгенә алдан язылу буенча күрсәтелә. Дәүләт хезмәте күрсәтү көнен һәм вакытын килештерү мәшгульлек үзәгенә

шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта яки телефон яки электрон элемтә чараларын, шул исәптән Интернет челтәрен, почта элемтәсен дә кертеп, гаризаны теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

2.4.9. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

## 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гаризасы (алга таба – гариза) яисә мәшгульлек үзәгеннән бирелгән, 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган формада дәүләт хезмәте күрсәтү тәкъдиме (алга таба – тәкъдим) белән ризалык.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, Россия Федерациясе гражданины паспорты яисә аны алмаштыра торган документны, чит ил гражданины, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклый торган документны күрсәтә.

2.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы мәшгульлек үзәгенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы порталында урнаштырылган. Мөрәҗәгать итүчегә гариза тапшыру ысулын сайлау мөмкинлеге тәэмин ителә: халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, почта аша, электрон почтаны да кертеп, факсимиль элемтә ярдәмендә яисә гади электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында, шул исәптән Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып, яисә гаризаны күпфункцияле үзәк, читтәге эш урыны аша тапшыру юлы белән.

2.5.3. Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле килештерүләрне дә кертеп, һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итүгә бәйле гамәлләр башкаруны, 210-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән исемлекләргә кертелгән хезмәтләрне күрсәтү һәм әлеге хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсендә бирелә торган документларны һәм мәгълүматларны алудан тыш;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм

мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Организмындагы бозылган функцияләрне һәм яшәешендәге чикләүләрен исәпкә алып, инвалид өчен медик-социаль экспертиза федераль дәүләт учреждениеләре (алга таба – МСЭ учреждениесе) тарафыннан киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлау өчен кирәкле, инвалидлык турындагы белешмәләрне үз эченә алган индивидуаль тернәкләндерү программасыннан өземтә мәшгульлек үзәге белән МСЭ арасында ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча ведомстволар арасында электрон хезмәттәшлек тәртибендә Инвалидларның федераль реестрыннан алына.

2.6.2. Тиешле мәгълүматлар Инвалидларның федераль реестрында булмаса, МСЭ учреждениесеннән бирелгән индивидуаль тернәкләндерү программасын инвалид үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы.

2.6.3. 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагында булган белешмәләрне үз эченә алган документларның тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе булып тормый.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Россия Федерациясе гражданины паспортын яки аны алмаштыра торган документның, чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документларның, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклый торган документларның булмавы яки аларны күрсәтүдән баш тартуы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар әлеге Регламентка 3 нче кушымтадагы форма буенча рәсмиләштерелә.

### 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән очракта чират көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.12.2. Мөрәҗәгать итүчеләр белән мәшгульлек үзәгенә яисә КФҮ мөрәҗәгать итү көнен һәм вакытын килештерү телефон яки электрон элемтә чараларын, шул исәптән Интернет челтәрен, почта элемтәсен дә кертеп, гаризаны теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

2.12.3. Мөрәҗәгать итү датасы һәм вакыты алдан килештерелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне көтү вакыты 5 минуттан артмаска тиеш.

### 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада

2.13.1. Гариза һәм документлар килгән көнне.

2.13.2. Гаризаны теркәү халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар (физик затлар, эш бирүчеләр) регистрына

мөрәҗәгать итүче (гражданин, эш бирүче) тапшырган документларда булган белешмәләрне исәпкә алу язуының теркәү номерын беркетеп кертү дигән сүз.

2.13.3. Мөрәҗәгать итүчеләр өчен гаризаны тапшыру ысулын сайлау мөмкинлеге тәэмин ителә: мәшгульлек үзәгенә яки күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына шәхсән мөрәҗәгать итеп, факсимиль элемтә чараларын кулланып яки электрон формада, шул исәптән Республика порталы аша.

2.13.4. Мөрәҗәгать итүченең (гражданин) таләбе буенча гаризаны кабул итү датасы һәм исәпкә алу язуының теркәү номеры турында белешмәләрне үз эченә алган гариза күчермәсе бирелә ала.

2.13.5. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.7.1 пунктында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән хезмәт күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектлардан һәм күрсәтелә торган дәүләт хезмәтеннән

каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтләре күрсәтү мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) хезмәт һәм мәшгульлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар һәм оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә комачаулый торган каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә)

мөмкинлеге яки андый мөмкинлекнең булмавы.

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:

мөрәҗәгать итүче өчен индивидуаль яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү рәвешендә (шәхси кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларын кулланып, массакүләм мәгълүмат чараларында мәкаләләр, мәгълүмати материаллары (брошюралар, белешмәлекләр, буклетлар һ.б.) нәшер итү юлы белән) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турында Татарстан Республикасы порталында мәгълүмат урнаштыру мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүче өчен дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаларның һәм башка документларның формаларын алуны, шул исәптән аларны күчереп алу һәм электрон рәвештә тутыру мөмкинлеге белән дә, тәэмин итү;

гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтү вакытының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, шул исәптән телефон элемтәсе, электрон почта аша, Татарстан Республикасы порталы, күпфункцияле үзәк, КФҮ ерактагы эш урыны аша, ерактагы эш урыны, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүмат алу мөмкинлеге;

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачаулаган каршылыкларны бетерүдә ярдәм итү;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

мәшгульлек үзәге тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнарындагы мәҗбүри таләпләрнең, дәүләт хезмәте күрсәткәндә әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлеше;

дәүләт хезмәте күрсәтү срокларының үтәлүе;

әлеге Регламентта билгеләнгән административ процедураларның эзлеклелеге саклану;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезлелеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы.

2.15.3. Мөрәҗәгать итүченең мәшгульлек үзәге белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

документларны почта аша җибәргәндә, шул исәптән электрон документ формасында да – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.15.4. Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы әлеге Регламент белән билгеләнә.

2.15.5. Күпфункцияле үзәктә, ерактагы эш урынында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.15.6. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гариза теркәлгән көннән соңгы эш

көненнән дә соңга калмыйча мәшгульлек үзәгенә тапшырыла.

2.15.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, КФҮ аша алынырга мөмкин

2.15.8. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплексы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

2.16.1. Техник мөмкинлек булган очракта, әлеге Административ регламентның 3.1.1 пунктының 1 - 7, 11 - 12 пунктчаларында каралган административ процедуралар (гамәлләр) электрон формада башкарыла.

2.16.2. Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар мәшгульлек үзәге бүлекчәсенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан мәшгульлек үзәгенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закондагы (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш»;

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны (гамәлләрне) дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре.

3.1.1 пунктның 12 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) аларны гамәлгә ашырган вакытта мөрәҗәгать итүченең профессиональ һәм эшкуарлык эшчәнлегенә уңышлы ирешә алуы мөмкин булган һөнәри эшчәнлекнең, мәшгульлекнең һәм компетенцияләрнең киңәш ителә торган, билгеле бер өлкәдә һөнәри эшчәнлек алып бару һәм (яки) конкрет һөнәрләр, белгечлекләр буенча эшләр башкару мөмкинлеген бирә торган төрләрен, һөнәргә укыту һәм (яки) йөнәри белем, өстәмә һөнәри белем алуның мөмкин булган юнәлешләрен үз эченә алган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы бәяләмәне (дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә) бирү; дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы бәяләмә нөсхәсен мөрәҗәгать итүченең шәхси эшенә теркәп кую;»

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи

затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.3 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шикаять почтадан, күпфункцияле үзәктән, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы порталы (http://uslugi.tatarstan.ru/), Бердәм портал (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта, «Интернет» челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең (http://mfc16.tatarstan.ru) рәсми сайты, Татарстан Республикасы порталы (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм портал (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.»;

6 нчы бүлекне гамәлдән чыккан дип танырга;

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты ярашлы булуы турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 19 октябрендәге 962 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 31.05.2019 №414, 16.11.2019 №1042, 13.07.2020 №497, 28.09.2020 №675, 13.11.2020 №791, 07.06.2021 №403 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты ярашлы булуы турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.3.4 пунктның 2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла.»;

1.5 пунктның дүртенче абзацында «(«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон))» сүзләрен «(«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон)) нигезендә тапшырылган»)  сүзләре белән алмаштырырга»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү.

2.2. Башкарма хакимият органының атамасы

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

2.3.1. Социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммерциясез оешмалар – иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүчеләр реестры турында» 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Социаль юнәлешле коммерциясез оешманы иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүче буларак тану турында карар кабул итү кагыйдәләренә (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр) 2 нче кушымтадагы форма буенча бәяләмә бирү яисә әлеге Регламентның 2 нче кушымтасындагы форма буенча социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белдерү (алга таба – бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белдерү) җибәрү.

2.3.2. Әлеге Регламент нигезендә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе документ формасында кәгазьдә, шулай ук көчәйтелгән квалификацияле электрон имзадан файдаланып, вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан имзаланган электрон документ рәвешендә бирелергә мөмкин.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт

хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Бәяләмә бирү турында гариза алынган көннән башлап 30 көн эчендә.

2.4.2. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә Министрлык тарафыннан рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрелгән очракта, әлеге вакыт озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән артыгракка түгел.

2.4.3. Әлеге карарны кабул итү вакытын арттыру турында Министрлык мөрәҗәгать итүчегә бәяләмә бирү турында оешмадан гариза алынган көннән башлап 30 көн эчендә хәбәр итә.

2.4.4. Бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү оешмага аны министр имзалаган көннән башлап өч эш көне эчендә җибәрелә.

2.4.5. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча гариза.

2.5.2. Гаризада коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү критерияләренә туры килүе нигезләнә:

күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтнең Россия Федерациясе норматив хокукый актларында аның эчтәлегенә (күләменә, срокларына, күрсәтү сыйфатына) карата билгеләнгән таләпләргә туры килүе;

иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән коммерциясез оешмалар хезмәткәрләренең һәм граждани-хокукый холыклы килешүләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән һөнәри юридик белеменең, тиешле өлкәдәге эш тәҗрибәсенең) булуы, мондый затларның тиешле санда булуы ;

иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтелә торган затларның аларны күрсәтү сыйфатыннан канәгать калуын раслау (коммерциясез оешмаларның формалаштырыла торган реестрына кертү турында гариза тапшырыла торган елдан алдагы 2 ел эчендә коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүгә бәйле оешма гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яки) карарларына суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләренә туры китереп, башка органнар тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләрнең булмавы;

коммерциясез оешма турында мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы;

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы

Федераль закон) нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында гариза бирелгән елга кадәр ике ел дәвамында социаль юнәлешле коммерциясез оешманың хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэминатчылар реестрында булмавы.

2.5.3. Гаризага оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча билгеләнгән критерияләргә туры килүен нигезли торган документлар (белешмәләр, характеристикалар, эксперт бәяләмәләре, мәнфәгатьле органнар каршындагы иҗтимагый советларның бәяләмәләре һ.б.) теркәлә ала.

2.5.4. Вәкаләтле затлар өчен ышаныч кәгазенең күчермәсе, әгәр гариза вәкаләтле зат тарафыннан бирелсә.

2.5.5. Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

2.5.6. Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

2.5.7. Документларның күчермәләре органнар һәм (яисә) документны биргән оешмалар тарафыннан таныклап тапшырыла.

2.5.8. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

2.5.9. Гариза почта аша җибәрелгәндә, аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга тиеш.

2.5.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.5.11. Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

2.5.12. Әгәр социаль юнәлешле коммерциясез оешма тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт төре буенча социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче затлар реестрына кертелгән булса, оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча билгеләнгән критерийларга туры килүен нигезли торган өстәмә документларны тапшыру таләп ителми.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү турында гариза тапшырылганчыга кадәр ике ел эчендә социаль юнәлешле коммерциясез оешманың 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә намуссыз тәэминатчылар (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмавы турында белешмәләр ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша (Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән) алына.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләре булган документларны, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча билгеләнгән критерияләргә туры килүен раслый торган документларны (белешмәләр, характеристикалар, эксперт бәяләмәләре, иҗтимагый советларның бәяләмәләре, дипломнарның һәм рәхмәт хатларының күчермәләре, кирәкле башка документлар), шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон формада да үз инициативасы белщн тапшырырга хокуклы.

2.6.3. Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торган документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.4. Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

Министрлык мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актлар нигезендә тапшырылуы каралмаган документлардан тыш, югарыда санап үтелгән, дәүләт хезмәтләрен күрсәтә торган органнар, муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле администрацияләр һәм җирле үзидарәнең башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган башка органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүдә катнаша торган федераль башкарма хакимият органнары, бюджетка карамаган дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары, шулай ук җирле үзидарә органнары карамагында булган документларны тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен

күрсәтү турында гариза бирүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартылганнан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренчел баш тарткан очракта дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи затының ялгыш яки хокукка каршы килә торган гамәлләр башкаруы (гамәл кылмавы) буенча документ нигезендә расланган факты (билгеләре) булуы ачыкланган очракта, бу хакта дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, шулай ук әлеге уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре юк.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк.

2.8.3. Бәяләмә бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

1) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүнең Россия Федерациясе норматив хокукый актларында аның эчтәлегенә (күләменә, срокларына, күрсәтү сыйфатына) карата билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

2) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры катнаша торган затларның (шул исәптән оешмаларның хезмәткәрләренең һәм граждани-хокукый холыклы килешүләр нигезендә җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән югары юридик белеме, юридик өлкәдә эш тәҗрибәсе) булмавы, кирәкле квалификациясе булган затларның исәбе буенча җитешеп бетмәве;

3) бәяләмә бирелә торган елга кадәрге 2 ел эчендә оешманың аның тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештәге гамәлләренә (гамәл кылмавына һәм (яки) карарларына карата суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләренә туры китереп, башка дәүләт органнары тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләр булуы;

4) оешма турындагы мәгълүматның ачык һәм аннан файдалана алу дәрәҗәсенең Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (алар булган очракта) туры килмәве;

5) бәяләмә бирелгән елга кадәрге 2 ел эчендә оешма турында «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэминатчылар реестрында мәгълүмат булуы;

6) дөрес булмаган белешмәләр булган документларны яки тиешенчә рәсмиләштерелгән документларны тапшыру.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

## 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

2.11.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган башка хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү каралмаган.

## 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Гариза белән документларны тапшырганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмый.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү 5 минуттан артык була алмый.

## 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада

2.13.1. Гариза алынган көнендә Министрлыкта теркәлә.

2.13.2. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар почта юлламасы яки электрон документ (документлар пакеты)

рәвешендә Министрлыкның эш сәгате тәмамланганнан соң килсә, аларны алу көне булып киләсе эш көне санала. Әгәр гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) ял көне яки бәйрәм көнендә алынса, аларны алу көне булып киләсе эш көне санала.

2.13.3. Гариза тапшыру көне булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән барлык документлар тапшырылган көн санала.

2.13.4. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.3.5 пунктында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән хезмәт күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектлардан һәм күрсәтелә торган дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны,

шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктала хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтләре күрсәтү мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) хезмәт һәм мәшгульлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар һәм оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә комачаулый торган каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктала хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) яки күрсәтеп булмау мөмкинлеге

2.15.1. Министрлык дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын үтәү юлы белән, шулай ук Регламентта билгеләнгән дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен үтәп, дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын һәм файдалана алырлык булуын тәэмин итә.

2.15.2. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

бүлмәләрнең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/) тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.

2.15.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Министрлык белгечләре тарафыннан әлеге регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.15.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итүенең вакыт озынлыгы 15 минуттан артмый.

2.15.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.

2.15.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республика порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/), КФҮ алынырга мөмкин.

2.15.7. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр.

Гариза һәм документлар Министрлыкка, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып электрон документ формасында җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш;

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны (гамәлләрне) дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре.

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе».